ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

"28" ноябрь, 2019 ел №2091

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 08 февралендәге 45 номерлы карары белән расланган муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 07 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру, җайга сала торган карарлар әзерләү һәм кабул итү өлешендә муниципаль идарә процессларының нәтиҗәлелеген күтәрү, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 8 февралендәге 45 номерлы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 8 февралендәге 45 номерлы карары белән расланган муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 2.2 бүлегендә түбәндәге эчтәлекле 17 пунктча өстәргә:

"Актлар проектларының конкуренция торышына йогынтысын анализлау».

2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.4.5 пункт өстәргә:

Акт проектын әзерләүче тискәре нәтиҗә белән килешмәсә, җайга салу аны килештерүче органнар җитәкчеләре белән үзара кулай чишелеш эзләү максатыннан фикер алышу ярдәмендә башкарыла. Шуңа бәйле рәвештә Килешү киңәшмәсе беркетмәсе рәсмиләштерелә, ул акт проектына кушыла һәм аны эшләүче җитәкчесе һәм вәкаләтле бүлек җитәкчесе кул куя».

2.Әлеге карарны «Лениногорские вести» рәсми публикатор-газетасында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында - http://leninogorsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Җитәкче З. Г. Михайлова

И. Р. Хәйбрахманов
5-44-72